

## *Рамазан ае кайтавазлары* *//Безнең бәйрәмнәр//*

Ураза гаетен 20нче мартта каршыладык. Без ураза тоттык, мәчеткә гаиләбездән 6 кеше намазга йөрде. Безне ике тапкыр ифтарга да чакырдылар. Баштан мәктәптә Гөлүсә апа белән Рафик абый уздырды, аннан Гөлшат апа да безне ифтарга чакырды. 21нче март көнне мәчеттә гаетне зурлап үткәрдек. Иң беренче ярминкә булды, анда күп товарлар сатылды. Аннан соң гает бәйрәменең төп өлеше булды. Без Коръән сүрәләре укыдык. Аннан Рафик абый мәчеткә тәравихка йөрүчеләргә күп итеп күчтәнәчләр өләште. Рамазан бәйрәмендә туганнардан да, әнидән дә бүләкләр алдым. Мин ураза көннәрен сагынам да инде.

*Айшә Галиаскәрова, V сыйныф укучысы*

Без гаетне мәчеттә үткәрдек. Иң беренче ярминкә булды. Балалар тәмле, татлы ризыклар саттылар. Аннан соң барыбыз да мәчеткә кердек. Алдан ятланган сүрәләр укыдык, кул эшләребезне күрсәттек. Бу эшләребез өчен безгә күп бүләкләр бирделәр. Ахырдан без тәмле пылау һәм коймак ашадык. Өстәл көйләүчеләргә һәм бәйрәмне оешытучыларга бик зур рәхмәт.

*Мөгаззәмә Нурматова, V сыйныф укучысы*

## *Күрше хакы турында* *//Укучылар иҗаты//*

Халыкта “Күрше хакы – Алла хакы” – дигән әйтем бар. Чыннан да күршеләр алдында хакларыбыз шул дәрәҗәдә олымы икән? Әйе, дөрестән дә шулай. Бүгенге көндә күпләр өчен хәтта күршеләр белән исәнләшү дә зур авырлык булып тора. Күбесенчә мондый очраклар шәһәрләрдә чагыла. Без, дөньяви мәсьәләләргә күмелеп, еш кына үз күршеләребез турында онытабыз. Инде күршеләр белән нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлеген ачыклар өчен дини чыганакларны карап китик әле.

Аллаһының илчесе Мөхәммәд (с.г.в) болай әйткән: ”Җәбраил миңа күршеләр хакы турында шулкадәр күп сөйләде ки, мин аларны варислар рәтенә кертер дип уйладым.” Бу хәдис күршеләрнең зур дәрәҗәдә булганын аңлата. Чөнки пәйгамбәребез күршеләр һәм туганнарга карата мөнәсәбәт тигез дәрәҗәдә дип уйлаган.

Тагын бер хәдистә: ”Янында ач күрше булганда, тук килеш йоклап киткән кеше мөэмин түгел” – диелгән. Бу хәдис күршеләргә карата игътибарлы кайгыртучан һәм ярдәмчел булырга өнди. Шуның белән мөэмин булган кеше үз күршеләренә яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш.

Югарыда китерелгән хәдисләрне карап, шундый нәтиҗә ясыйсы килә: Мөэмин-мөселман булган кеше күршеләренә карата бик яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш.

*Хәнифә Хәбибрахманова, IX сыйныф укучысы*



*//Безнең уңышлар//*

## «*Тере классика» һәм “Без бергә”*

Балалар китап уку белән кызыксынсыннар, өстәмә әсәрләр белән танышсыннар өчен ел саен районда “Тере классика” дигән конкурс үткәрелә. Быел ул Аксубайның 3нче мәктәбендә узды. Бирегә районның барлык мәктәпләреннән дә иң оста сөйләүчеләр җыелды. Безнең мәктәптән **Вәлиев Ибраһим** һәм **Насыйрова Кәүсәр** призёр исемен алдылар. Алар бу конкурстан инде берничә ел рәттән алдынгы урыннар белән кайталар. Беренче тапкыр катнашуга карамастан, сыйныфташым **Сафиуллина Гөлсем** дә бик уңышлы чыгыш ясады. Тик аңа урын бирмәделәр.

25 мартта үземнең дусларым белән Аксубайның 2нче мәктәбенә “Без бергә” дип аталган фестивальдә катнашырга бардык. Бу чарага районның барлык мәктәпләреннән иң сәләтле балалар җыелган иде. Катнашучылар халык вокалы (соло), халык вокаль ансамбле, хореография, сәнгатьле уку, театр кую буенча ярыштылар. “Сәнгатьле уку” буенча IX сыйныфтан Вәлиев Ибраһим I урынны һәм безнең сыйныфтан **Сафиуллина Гөлсем** III урыннарны алдылар. "Халык ансамбле" номинациясендә Артур белән без **"Майна егетләре"** дуэты булып җырлап, III урынны алдык. Конкурска барган саен урын яулап кайту кызык икән. Ибраһимга бөтен район укучылары да соклана. Без дә аның кебек матур сөйләргә өйрәнсәк иде.

*Инсаф Закиров, V сыйныф укучысы*



*//Котлыйбыз!//*

Март аенда дөньяга килгән дусларыбыз III сыйныфтан **Хәбибрахманова Асия** белән **Нурматова Мәдхияне**, VI сыйныфтан **Хусенов Диманы**, VIII сыйныфтан **Әхсәнова Мәдинәне,** IX сыйныфтан **Вәлиев Ибраһимны** туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга исән-сау булып, тырышып белем алуларын телибез.

Шулай ук, газетабезнең мөхәррире, татар теле укытучысы **Гафиятуллина Фәнүзә апаны** гомер бәйрәме белән котлап, ныклы исәнлек, мактаулы эшендә зур уңышларга ирешүен теләп калабыз!

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева.**

# Мәктәп хәбәрчесе

**№3**
**(№74)**
**март**
**2026 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

## *III чирек нәтиҗәләре* *//Рәсми хәбәрләр//*

III чиректә 38 балага чирек билгеләре чыгарылды. 18 укучы өченче чирекне «4» һәм «5» билгеләренә тәмамлады. «5»ле билгеләренә IV сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**, V сыйныфтан **Камалов Илнур** белән **Закиров Инсаф**, VI сыйныфтан **Нурматова Асия**, VIII сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, IX сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил** тәмамлады. Гомуми нәтиҗәләр буенча белем сыйфаты 63,16% тәшкил итте. Язгы каникулар 28 марттан 6 апрельгәчә булачак.

*Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары*

*//Безнең спорт//*



Каникулның беренче көнен укучыларыбыз көрәш мәйданында каршылады. 28нче март көнне Аксубай районының милли көрәш буенча ачык турниры булып үтте. Локаль хәрби конфликтлар ветераннары истәлегенә багышланган иде әлеге чара **Түбән Майна яшьләре призына** уздырылды. Ярышлар Аксубайның “Яшьлек” спорт комплексында үткәрелде һәм бик күп яшь спортчыларны җыйды. Бәйгедә Норлат, Чистай, Чирмешән һәм Аксубай районнарыннан 60 көрәшче катнашты.

Безнең мәктәптән турнирда катнашкан 11 укучының 9ы төрле дәрәҗәдәге урыннар алып кайтты: **Нургатин Фаил** (V сыйныф) белән **Хәбибрахманов Абдулла** (VII сыйныф) – I урын; **Камалов Илнур** (V сыйныф), **Замалетдинов Зөлфәт**, **Сәгъдиев Рәмзис** (VII сыйныфлар) – II урын; **Хафизов Илфат** (IV сыйныф), **Закиров Инсаф** (V сыйныф), **Хусенов Дима** (VI сыйныф), **Нурматов Салман** (VII сыйныф) – III урын. Елисеев Адел (I сыйныф) белән Хәйрулин Мансур (III сыйныф) урыннар алмасалар да, матур көрәш күрсәттеләр. Барлык спортчыларга да тырышлыклары һәм җиңүгә омтылышлары өчен рәхмәт белдерәбез! Аеруча зур рәхмәтебез – көрәшчеләрне әзерләгән **Камалов Ильһам Илгизәр улына**.




20 марттан 30 мартка кадәр безнен мәктәп укучысы **Фаил Гафиятуллин** Чаллы шәһәренең "Этюд" шахматлар мәктәбе җирлегендә узган шахмат буенча Идел буе Федераль округы (ПФО) чемпионатында көч сынашты. Уеннар өч төрдә узды: классик, рапид, блиц. Уенчылар арасында Идел буе Федераль округына караучы барлык регионнардан да көчле уенчылар катнашты. Классик төрдә көрәш 9 турдан, рапид буенча, шулай ук, 9 турдан, блиц – 11 турдан торды. Уеннар нәтиҗәсе буенча Фаил спорт мастерына кандидат (КМС) дәрәҗәсе нормативларын үтәүгә ирешә. Фаилне зур уңышы белән тәбрик итәбез!



## *Кеше хезмәтенең кадере* *//Мөхәррир минбәре//*

Кеше хезмәте – ул безнең тормышыбызның нигезе. Көн дәвамында без төрле эшләр башкарабыз: укыйбыз, эшлибез, яраткан шөгыль белән вакыт үткәрәбез. Һәрберле хезмәт кемнеңдер тормышын яхшырту, җиңеләйтү өчен эшләнә. Төзүчеләр йортлар сала, табиблар авыруларны дәвалый, укытучылар белем бирә, игенчеләр ашлык үстерә. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күрү – үзе бер зур шатлык. Кешене хезмәт үстерә, аңа яңа мөмкинлекләр ача, аны тәрбияли. Үз-үзебез өчен җавап бирергә дә безне хезмәт өйрәтә.

Бу борчулы язманы янәшәбездә безнең өчен башкарылган хезмәтне күрә белмәүчеләр булуына ачынып яздык. Мәктәптә укучылар өчен барлык шартлар тудырылган. Алар чиста, җыештырылган бинага килә. Ашарларына кайнар ризык әзер. Уку бүлмәләре шулай ук җылытылган. Менә шушы хезмәтләрне башкарган **КЕШЕЛӘРНЕ** дә хөрмәт итәргә өйрәтә алсак иде. Мәктәп милкен саклауның никадәр дәрәҗәдә мөһим икәнлеген даими искә төшереп торсак та, аңа караш әлләни яхшы якка үзгәрмәде. Һаман парталарга, тәрәзә төпләренә, туалет ишекләренә бер-берсен кимсетеп язу калдыруларны дәвам итәләр. Иң куркынычы – алар үзләренең гаепләрен танымый, аның өчен җавап бирергә дә уйламый. Үз гаебең өчен җавап бирмәү – куркаклык билгесе. “Кырын эш кырык елдан соң да беленә” – диелә халык мәкалендә. Үз мәктәпләренә зыян итүче куркакларның да гаебе иртәме-соңмы ачылачак бит. Кеше хезмәтен кадерли белмәүчеләрнең үзләрен кемдер хөрмәт итәрме икән?

Мәктәп тормышындагы кимчелекләр турындагы мәкаләләрне укучыларыбызны тәрбияле итеп күрәсебез килгәннән язабыз. Алар барысы да безнең өчен бертигез дәрәҗәдә кадерле. Тәртипсезләр дә, үз гаепләрен танып, китергән зыянны каплап, киләчәктә бозык эшләрдән баш тартсалар, без кичерә беләбез.

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*



## Изгелек җирдә ятмас!

6нчы мартта VI сыйныф укучылары, тәрбия буенча киңәшче Әхмәтҗанова Гөлфия апа белән берлектә, **"Сезгә, яратканнар!"** акциясе кысаларында уздырылган Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган чарада катнаштылар. Алар Тәнзилә әбигә барып, аны бәйрәм белән котладылар һәм аңа үз куллары белән ясалган чәчәкләр бәйләме тапшырдылар. Очрашу вакытында балалар аның балачагы турында тыңладылар һәм кыйммәтле тормыш киңәшләре алдылар. Очрашуда ясалган фотолар әлеге вакыйга турында истәлек булып калды. Чара шулай ук, өлкән буыннарның хезмәтен хөрмәтләү һәм тануның мөһимлеген ассызыклап, хезмәт батырлыгы елы белән бәйле булды. Шулай итеп, әлеге очрашу яшьләргә өлкән буыннарга үзләренең ихтирамын белдерергә, буыннар арасындагы элемтәне ныгытырга һәм мәдәни традицияләрне үстерүгә ярдәм итә торган мөһим вакыйгага әверелде. Бу тәҗрибә балаларда өлкән буынга карата җаваплылык, рәхмәт һәм хөрмәт хисе тәрбияләргә ярдәм итә, бу тәрбиянең мөһим өлеше булып тора.

---



6 нчы март көнне **"Игелекле эшләр атнасы"** акциясе кысаларында VII сыйныф укучылары тәрбия буенча киңәшче Әхмәтҗанова Гөлфия апа җитәкчелегендә ялгыз яшәүче инвалид Айна апага ярдәм итәргә бардылар. Укучылар дәресләрдән соң аның өенә килеп, ишегалды территориясен тәртипкә китерергә булыштылар. Бик тырышып эшләп, ишегалдын кардан чистарттылар. Айна апа укучыларга чын күңелдән рәхмәт белдерде. Аны шатландыру балалар өчен дә бик рәхәт иде.

---



**"Сезгә, яратканнар!"** Бөтенроссия акциясе кысаларында атна дәвамында безнең мәктәп малайлары бары тик игелекле эшләр генә башкарырга булдылар. Алар 8нче март хөрмәтенә кызларга үз куллары белән бүләкләр ясадылар. Барлык әзерләнгән бүләкләр җылы теләкләр белән бергә кызларга тапшырылды. Котлауның мондый ысулы шәхсән катнашуның һәм бер-береңә игътибарлы булуның мөһимлеген күрсәтә.

***Вакыйгаларны редколлегиясе әгъзалары туплады***

---

## Мәктәптә математика декадасы



Борынгы заманнардан ук билгеле булганча, математика безне дөрес һәм логик фикер йөртергә өйрәтә. Кем балачактан ук математика белән шөгыльләнә, ул үз акылын, игътибарын үстерә. Укучыларның математика фәне белән кызыксынуын арттыру, иҗади һәм интеллектуаль сәләтләрен үстерү максатыннан мәктәптә 16-25 март көннәрендә Н.И.Лобачевскийга багышланган "Мәктәптә математика декадасы" үткәрелде. Бу “ункөнлек” кысаларында атналыкның ачылышы булды. VI-VII сыйныф укучылары арасында "Математик кроссворд" уены үткәрелде. Укучылар сорауларга җавап бирделәр һәм кроссворд сүзләрен чиштеләр. Өлкән сыйныфлар арасында “Көчсез буын” уены узды. Башлангычларда 19нчы мартта “Күңелле математика” исемендә КВН булды. Бөек рус математигы Н.И.Лобачевскийның тормышына карата презентация күрсәтелде. 23нче мартта финанс грамоталылыгы (Саннарның грамоталы финанс чишелешенә ярдәме турында) мастер-класс үткәрелде. Чара нәтиҗәләре буенча җиңүче билгеләнде. 24нче мартта V сыйныфлар арасында геометрик фигураларны өйрәнү буенча ачык чара узды. Укучылар әлеге чарада актив катнаштылар, математика фәненнән үзләренең белемнәрен сынадылар. 25нче мартта уздырылган атналыкка нәтиҗәләр ясалды һәм ахырдан үзләренә файдалы бүләкләр тапшырылды.

***Алсу Сафиуллина, математика укытучысы***

---

## Шигърият көне чаралары

21нче март көнне Бөтендөнья шигърият көне алдыннан безнең мәктәптә тәрбия буенча директор киңәшчесе Әхмәтҗанова Гөлфия апа белән берлектә Якты чаралар узды, алар барлык катнашучыларга уңай хис-кичерешләр бүләк итте. Кече мәктәп укучылары өчен “Рифмалы зарядка” уены оештырылды. Балалар рәхәтләнеп музыкага зарядка ясадылар һәм шигырьләр тыңладылар.

Татар теле кабинетында "Ачык микрофон” чарасы үткәрелде. Укучылар бөек татар һәм рус шагыйрьләренең яраткан шигырьләрен укыдылар. Аларның чыгышы күңелне нечкәртерлек һәм күңелле яңгырады. Барлык балаларга да катнашулары, ихласлыгы һәм шигъриятькә мәхәббәте өчен рәхмәт! Рифмалар ешрак яңгырасын, әлһам бетмәсен!

---






## Рамазан ае кайтавазлары

Озын төннәр кыскара, каты салкыннар, ачы бураннар сирәгәя, кыш әкрен генә китәргә җыена торган вакыт. 19нчы февраль бар мөселман кешесе көтеп алган изге ай – Рамазан быел кышның шул вакытына туры килде. Безнең авыл халкы барысы да диярлек ураза тотарга тырышты, күп гаиләләр ифтар ашлары уздырды. Һәр кичне азан ураза тотучыларны тәравих намазларына чакырды. Мәчет бер дә буш булмады: олысы да, кечесе дә гел йөреп торды. "Рамазан ае уразасы ихлас күңел һәм савабын бары тик Аллаһыдан гына өмет итеп тоткан кешенең кылган гөнаһлары ярлыканыр" – дип әйтелә бит хәдистә. Шундый ниятләр белән бу ай сизелми дә үтеп китте.

21 нче март иртәсендә табәнәк, болаңгыр күктә ягымлы кояш күренде. Тирә - якны куанычка, шатлыкка күмеп, авыл халкы җомга көненә туры килгән гает намазына җыелды. Ә бәйрәмнең икенче көнендә Рамазан аен озату хөрмәтенә мәчеттә балалар өчен бәйрәм уздырылды. Чара мәктәп ярминкәсе белән башланып китте. Балалар әти-әниләре белән бергәләп әзерләгән төрле-төрле тәмле ризыклар, сыерчык оялары сатты. Шул ук вакытта борыннарны кытыклап учакта тәмле пылау пеште. Гает бәйрәме хөрмәтенә балалар бакчасы, мәктәп укучылары, хәтта килгән кунаклар да мәчет түрендә чыгыш ясадылар. Кечерәкләр сүрәләр ятлап сөйләде, зурлар төрле темаларга вәгазь әзерләде.

Балаларның тырышлыклары бәясез калмады. Һәр чыгыш ясаган, һәр кул эше әзерләгән укучыга мәчет тарафыннан күчтәнәчләр тапшырылды. Әмма иң зур бүләк алда иде әле. Рамазан ае дәвамында тәравих намазларына күп йөргән, ихлас күңелдән ураза тоткан мәктәп укучыларына тантаналы рәвештә зур бүләкләр өләшенде. Моңа карап кечерәк балаларда да киләсе елга ураза тотып тәравихка йөрү теләге уянгандыр.

Ахырдан Гает бәйрәменә килгән барлык кунаклар, авылдашлар табынга утырыштылар. Учакта пешкән тәмле пылау, хуш исле коймак һәм кайнар чәй һәркемнең күңелен күтәреп җибәрде. Кешеләр бер-берсе белән аралашып, шау-гөр килделәр. Ә тыштагы кыш соңгы салкын җилләрен өрде. Ләкин бу халыкның җылы мөнәсәбәтенә, изге бәйрәм рухына бер дә комачауламады. Бәйрәм менә шулай иманлы бердәмлектә, якты шатлык эчендә тәмамланды. Күңелләрдә якты кояш кебек нур һәм иман ныклыгы гына иде.

***Кәусәр Насыйрова, VIII сыйныф укучысы***

---

18нче март көнне укытучы Гөлшат апабыз безне үзләренә ифтар ашына чакырды. Кичке 5ләрдә барыбыз да аларга җыелдык. Иң беренче булып укытучы Алсу апа безгә файдалы вәгазь сөйләп дога кылды. Без үзебез дә аннан соң догалар укыдык. Намаз укыганнан соң авыз ачып тәмле ризыклар белән сыйландык. Гөлшат апа безгә бик күп төрле ризыклар әзерләгән иде. Безнең яраткан ризыгыбыз купаты да кыздырган иде. Ифтар вакытыннан соң мәчеткә тәрәвихка бардык. Ә күрше авыл балаларын Азат абый машинасы белән илтергә китте.

Гөлшат апага ифтар өчен зур рәхмәтләребезне әйтеп, сәламәтлек теләп калабыз.

***Илнур Камалов, V сыйныф укучысы***

---



21 нче мартта без Гает бәйрәмен үткәрдек. Мин ул бәйрәмне бик сагынып көттем көттем. Чөнки беренче тапкыр үзем ураза тота алдым. Шуңа да гает бәйрәме минем өчен олы тантана иде.

Иң беренче булып бу көнне мәчет йортында ярминкә башланып китте. Без өйдә пешергән татлы камыр ризыклары, туңдырма саттык. Авылдашлар, кайткан кунаклар товарларыбызны бик тиз алып бетерделәр. Шуннан соң мәчеттә бәйрәмнең төп өлеше башланды. Гает бәйрәменең төп өлеше матур азан тавышы белән башланып китте. Азанны минем энем Ислам әйтте. Кечерәк сыйныфларга Коръән сүрәләре өйрәнеп килергә кушылган иде. Шул биремнәрне теләп үтәдек, бәйрәмдә сүрәләрне яттан сөйләдек. VIII-IX сыйныфларга төрле темаларга вәгазь әзерләргә иде. Бәйрәмгә килүчеләр аларны да яратып тыңлады.

Укучыларның чыгышлары тәмамлангач, Рафик абый кул эшләребезне дә барлап, барыбызга да бүләкләр өләште. Мин Әл-Хәрам мәчетенең макетын ясаган идем. Мине шуның өчен чәк-чәк белән бүләкләделәр. Аннан соң өстәл тирәсенә җыелыштык. Чөнки Әнвәр абыйның барыбызны да пылау белән сыйлыйчагын белә идек. Укытучы апалар өстәл көйләгәннәр, пешерүче апаларыбыз коймак пешергәннәр иде. Без рәхәтләнеп аралашып, кайнар ризыклар белән сыйланганнан соң, гает бүләкләренә шатланышып, өйләргә таралыштык. Бәйрәм әле дәвам итә иде. Чөнки ел саен Рафик абый безгә һәрберебезә күп итеп күчтәнәч өләшә. Тәрәвих намазларына йөрүчеләргә, ураза тотучыларга күчтәнәчнең тагы да зуррагы эләгә.

Гаетне матур итеп, мул итеп уздыручыларга рәхмәтебез зур. Бүләк кенә түгел, авылдашлар, кунаклар белән аралашу мөмкинлеге дә әле ул бәйрәм.

***Гөлсем Сафиуллина, V сыйныф укучысы***